ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннаи һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ иомерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 8 (II өлеш), № 12 (X өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 12 (I өлеш); 2012, № 1, № 9; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 1 өлешендә:

а) «д» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) яшәү урыны буенча торак урында теркәлгән гражданнар санын раслаучы белешмәләр;»;

б) «ж» пунктчасында «орган (алга таба – хокукларны теркәү органы) белешмәсе» сүзләрен «органнан (алга таба – хокукларны теркәү органы) белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

2) 10 статьяның «ж» пунктчасында:

а) уникенче абзацта «акчалата түләүләр» сүзләреннән соң «(компенсацияләр)» сүзен өстәргә;

б) ундүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 12 статьяның 8 өлешендә «уңышлардан, продукциядән һәм керемнәрдән файдалану турында» сүзләрен «уңышларны, продукцияне һәм керемнәрне бүлү турында» сүзләренә алмаштырырга;

4) 14 статьяда:
а) 1 өлештә «исәпләнелә» сүзен «билгеләнә» сүзенә алмаштырырга;
б) 2 өлештә «исәпләнелә» сүзен «билгеләнә» сүзенә алмаштырырга;
в) 3 өлештә «исәпләнелә» сүзен «билгеләнә» сүзенә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 06 август
№ 63-ТРЗ